ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 9 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы ундүртенче абзацына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 95 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«ландшафт (табигый) янгыннарын (урман фонды җирләрендә, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарыннан тыш) сүндерү планнарын эшләү һәм раслау, шулай ук мондый янгыннарны сүндерүне Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә эшләүче гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән оештыру;».

## 2 статья

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү чараларын үткәрү, гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрне үлемнән коткаруга һәм аларның сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру.»;

2) икенче өлештә «егерме өченче» сүзләреннән соң «һәм егерме алтынчы» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 26 ноябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 17 октябрь
№ 85-ТРЗ